Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАРЫ

«26» ноябрь 2021 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2022 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Салдакай авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм ремонтлау;

Салдакай авылында янгын сүндерү машинасы өчен җылы гаражны ремонтлау һәм җиһазлау;

Салдакай авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче: Х.Х.Хәмидуллин

Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Хәмидуллин